РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2020 Буа шәһәре № 96-п

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Икътисади үсеш министрлыгының «Хуҗасыз күчемсез әйберләрне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 931 номерлы боерыгы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

Расларга:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибен (1нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча комиссиясе турында Нигезләмәне. (2нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча комиссия составын (3нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә буш торучы торак урыннарны, торак биналар һәм җир кишәрлекләре рәвешендә хуҗасыз, вариссыз калган мөлкәтне ачыклау буенча эшче төркем төзү турында» 2019 елның 5 августындагы 70-п номерлы карары үз көчен югалткан дип таныырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Камартдинов

«ТР Буа муниципаль районы
Башлыгының
«10» ноябрь 2020елның
96-п номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хуҗасыз күчемсез әйберләрне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» Россия Икътисади үсеш министрлыгының 2015 елның 10 декабрендәге 931 номерлы боерыгы нигезендә эшләнгән һәм түбәндәгеләрне билгели:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез милекне ачыклау тәртибе, аны исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе;

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә вариссыз калган мөлкәтне ачыклау һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе;

1.2. Әлеге тәртип кагыла түбәндәгеләргә кагыла:

- ТР Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан милекчесе билгесез яки милекчесе булмаган күчемсез милек, яки милекчесе күчемсез милеккә хокуктан баш тарткан, күчемсез милек;

- ТР Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан вариссыз калган мөлкәт.

1.3. Күчемсез милек объектларын хуҗасыз дип тану өчен документлар рәсмиләштерүне, хуҗасыз күчемсез милек объектларын исәпкә куюны һәм муниципаль милеккә кабул итүне Буа муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба –Җирлек башкарма комитеты) әлеге тәртип һәм Россия Федерациясе Граждан кодексы, башка норматив хокукый актлар нигезендә башкара.

1.4. Күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектларын ачыклау, ачыкланган хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектларына муниципаль милек хокукын рәсмиләштерү максатларына һәм бурычларына түбәндәгеләр керә:

- файдаланылмый торган милекне ирекле граждан әйләнешенә җәлеп итү;

- мөлкәтне нормаль һәм имин техник эксплуатацияләүне тәэмин итү;

- муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясен төзекләндерү һәм аның тиешле торышы;

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында билгеләнгән җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итү.

1.5. Әлеге Тәртип белән җайга салынмаган хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтене муниципаль милеккә кабул итү мәсьәләләре Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән җайга салына.

## 2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе

2.1. Хуҗасыз милек билгеләре булган күчемсез мөлкәт турындагы белешмәләр түбәндәгеләрдән керергә мөмкин:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан;
- инвентаризация үткәрү нәтиҗәсендә;
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының инженерлык инфраструктурасы объектларында ремонт эшләре башкарганда;
- юридик һәм физик затларның гаризалары нигезендә;
- башка ысуллар белән.

2.2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектларын ачыклау эшләрен оештыру Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча комиссиясе (алга таба - Комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның составы һәм нигезләмәсе муниципаль хокукый акт белән раслана.

2.3. Хуҗасыз ачыкланган күчемсез мөлкәт объектларын исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү җирлек башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Күчемсез милек объекты турында мәгълүмат алынган көннән алып 10 эш көне эчендә, Комиссия объектның урнашкан урынына барып, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә, хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау Акты төзеп, кергән мәгълүматны тикшерүне үткәрә.

2.4. Хуҗасыз күчемсез милек ачыклану Акты төзелгәннән соң, Җирлек башкарма комитеты 10 эш көне эчендә хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны төгәлләштерү һәм тулыландыру эшен башкара, күчемсез мөлкәт объектының милекчесе булмавын, яки аның милекчесе билгесез булуын яки милекчесенең аңа милек хокукыннан баш тартуын раслый торган документлар җыюны гамәлгә ашыра.

Күчемсез милек объектының милекчесе билгесез яки аның милекчесе булмавын раслаучы документлар булып тора:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән, әлеге күчемсез мөлкәт объекты федераль милек, Россия Федерациясе субъекты мөлкәте һәм муниципаль мөлкәт реестрларында исәпкә алынмаган документлар;
- Техник инвентаризация бюросы органнарында теркәлү хокуклары;

- тиешле дәүләт органнары (оешмалары) тарафыннан күчемсез милеккә хокукларны теркәүне гамәлгә ашыручы документлар, әлеге күчемсез милек объектларына хокуклар алар тарафыннан теркәлмәгән, дип раслый торган документлар;

- күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объекты турында белешмәләр.

2.5. Милекченең күчемсез милеккә хокуктан баш тартуын раслый торган документ булып, нотариаль таныкланган, милекчедән күчемсез милек объектына милек хокукыннан баш тарту турында гариза һәм бу мөлкәтне хуҗасыз сыйфатында исәпкә куюга ризалык (милекче бу милеккә милек хокукыннан баш тарткан очракта бирелә) тора.

Милекче-юридик зат мөлкәткә милек хокукыннан баш тарткан очракта һәм милек хокукы теркәлмәгән очракта, Комиссия ведомствоара багланышлар аша түбәндәге документларны соратып ала яисә ала:

- милек хокукыннан баш тарткан затның милек хокукы булуын раслый торган хокук билгели торган документларның күчермәләре;

- юридик затның гамәлгә кую документларының күчермәләре, юридик затның дәүләт теркәве турында таныклык, салым түләүченең идентификация номеры.

Милекче-физик затның милеккә хокукыннан баш тарткан очракта һәм милек хокукы теркәлмәгән очракта, җирлек башкарма комитеты ведомствоара бәйләнеш аша түбәндәге документларны ала:

- милек хокукыннан баш тарткан затның милек хокукы булуын раслый торган хокук билгели торган документларның күчермәләре;

сората:

- юридик зат төземичә генә эшмәкәр сыйфатында физик затны теркәү турында белешмәләр;

- гражданинның шәхесен таныклаучы документ күчермәсе.

2.6. Күчемсез милек объекты милекчесе турында мәгълүмат алган очракта, тиешле объектны исәпкә кую өчен документлар җыю эше туктатыла, бу хакта хуҗасыз күчемсез милек турында мәгълүмат биргән затка хәбәр ителә.

2.7. Әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, хуҗасыз күчемсез милек объекты турында мәгълүматларны тикшерү чаралары тәмамланганнан соң, 10 эш көне дәвамында, Җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күчемсез милек объектын хуҗасыз дип тану һәм аны ТР Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектлары реестрына кертү турында карар (алга таба – Реестр) чыгарыла.

2.8. Реестрны алып бару җирлек башкарма комитеты тарафыннан әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта белән расланган форма буенча башкарыла.

2.9. ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитетының күчемсез милек объектын хуҗасыз дип тану турындагы карары кабул ителгәннән соң 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, Җирлек башкарма комитеты кадастр паспортын һәм техник инвентаризация органнарында планнар әзерләүне заказ бирә. Техник инвентаризация үткәрү, кадастр һәм техник паспортлар әзерләү эшләре җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла.

2.10. Хуҗасызлык билгеләре булган мөлкәтнең җимерелүенә (юкка чыгуына) куркыныч янауны булдырмау, гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыра торган авария хәлләре барлыкка килү һәм аларны бетерү максатларында (яшәү белән тәэмин итү объектларын, инженерлык

инфраструктурасын һәм төзекләндерү объектларын тиешле хәлдә тоту өлешендә) Җирлек башкарма комитеты әлеге мөлкәтнең сакланышын җирле бюджет акчалары хисабына һәм чикләрендә тәэмин итә.

Күрсәтелгән хуҗасыз мөлкәткә муниципаль милек хокукын таныганчыга кадәр, ачыкланмаган җылылык челтәрләрен тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Ачыкланган хуҗасыз үзәкләштерелгән кайнар су белән тәэмин итү системаларының, салкын су белән тәэмин итү һәм (яисә) су бүлеп бирү системаларының, шул исәптән су белән тәэмин итү һәм (яисә) су белән тәэмин итү юлы белән тәэмин ителә торган сууткәргеч һәм канализация челтәрләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, күрсәтелгән хуҗасыз мөлкәткә муниципаль милек хокукы танылганчы яисә аларны биләүгә алганчы, мондый объектларны калдырган милекче тарафыннан Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә файдалану һәм эш итү «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.11. Ачыкланган күчемсез мөлкәт объектын исәпкә кую, Россия Икътисади үсеш министрлыгының «Хуҗасыз күчемсез әйберләрне исәпкә алу тәртибен билгеләү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 931 боерыгы нигезендә муниципаль мөлкәт бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.12. Хуҗасыз күчемсез мөлкәт объектын исәпкә куйган көннән алып бер ел үткәч, Җирлек башкарма комитеты мондый объектка муниципаль милек хокукын тану таләбе белән судка мөрәҗәгать итә.

2.13. Күчемсез мөлкәтнең хуҗасыз объектларын муниципаль милеккә кабул итү законлы көченә кергән суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла, ул әлеге Тәртипнең 2.12 пунктында күрсәтелгән гаризаны карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган.

2.14. Күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органда муниципаль милек хокукын дәүләт теркәвенә алу гамәлләре муниципаль милек хокукын тану турында суд карары законлы көченә кергән вакыттан алып 10 эш көне эчендә Җирлек башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.15. Муниципаль милек хокукын теркәгәннән соң, Җирлек башкарма комитеты 10 эш көне эчендә объектны Реестрдан төшереп калдыру һәм аны муниципаль мөлкәт реестрына кертү буенча чаралар үткәрә.

2.16. Муниципаль милек хокукын теркәгәннән соң, муниципаль мөлкәт бүлеге әлеге күчемсез милек объектлары астында җир кишәрлекләрен муниципаль милеккә рәсмиләштерү чараларын үткәрә.

3. ТБ Буа муниципаль районы территориясендә вариссыз калган мөлкәтне ачыклау һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе

3.1. Закон буенча муниципаль берәмлеккә мирас хокукы буенча күчүче варисыз калган мөлкәткә, закон буенча да, васыять буенча да варислар булмаган очракта, гражданнарга милек хокукында булган һәм алар үлгәннән соң азат ителгән, яисә варисларның берсенең дә мирас хокукы булмаган яки барлык варислар варислыктан читләштерелгән, яисә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яисә барлык варислар да мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе

дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән, шулай ук, әгәр мөлкәт муниципаль берәмлеккә васыять буенча тапшырылган милек карый.

3.2. Закон буенча мирас итеп алу тәртибендә гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль милеккә Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан түбәндәге варисыз калган мөлкәт күчә:

торак бина;

җир кишәрлеге, шулай ук анда урнашкан биналар, корылмалар, күчемсез мөлкәтнең башка объектлары;

әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына гомуми өлешле милек хокукындагы өлеш.

3.3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының варисыз калган мөлкәткә милек хокукын раслаучы документ нотариаль орган тарафыннан тапшырыла торган мираска хокук турында таныклык булып тора.

Варисыз калган мөлкәт алу өчен мирасны кабул итү таләп ителми.

3.4. ТР Буа муниципаль районы территориясендә вариссыз калган мөлкәтне ачыклау һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү эшләрен оештыру Җирлек башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.5. Вариссыз калган билгеләре булган күчемсез мөлкәт турындагы белешмәләр түбәндәгеләрдән керергә мөмкин:

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан;

- Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан;

- инвентаризация үткәрү нәтиҗәсендә;

- идарәче оешмаларның, башка юридик һәм физик затларның гаризалары нигезендә;

- башка ысуллар белән.

3.6. Вариссыз калган мөлкәт турында белешмәләр кергән вакыттан алып, 5 көн эчендә, Җирлек башкарма комитеты нотариаль органнарга мирас фактын билгеләү максатында запрос җибәрә.

3.7. Вариссыз калган мөлкәткә мирас алу хокукы турында таныклык бирүдә нотариус баш тарткан очракта, Җирлек башкарма комитеты муниципаль милек хокукын вариссыз калган мөлкәтне муниципаль милек дип тану турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итә.

3.8. Вариссыз калган мөлкәткә милек хокукы турында таныклык алганда яисә вариссыз калган мөлкәткә муниципаль милек хокукын тану турында суд карары үз көченә кергәндә Җирлек башкарма комитеты хокукларны теркәү органнарында вариссыз калган мөлкәткә муниципаль милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итә.

3.9. Күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвенә алганнан соң җирлек Башкарма комитеты:

- муниципаль милеккә кабул итү һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы казнасы составына вариссыз калган мөлкәтне кертү турында карар проектын әзерләүне тәэмин итә;

- муниципаль мөлкәт реестрына тиешле белешмәләр кертүне тәэмин итә.

3.10. ТР Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан торак урыннар рәвешендәге вариссыз калган мөлкәт (шул исәптән торак йортлар һәм аларның өлешләре) билгеләнгән тәртиптә теркәлгән милек хокукы социаль файдалануның торак фондына кертелә.

Хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган<br>мөлкәтне ачыклау,исәпкә алу һәм муниципаль<br>милеккә рәсмиләштерү<br>Тәртибенә 1 нче кушымта

РАСЛЫЙМ<br>ТР Буа муниципаль районы Башлыгы<br>_____________ /______________/<br>(имза) (Ф.И.А)<br>«___» ____________ 20____ел.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау буенча

А К Т

«__»________________ел. Буа шәһәре

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау комиссиясе түбәндәге составта:

____________________________________________________________________________

(анда катнашучы комиссия әгъзаларының ФИ Атасының исеме һәм вазыйфалары күрсәтелә)

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

________________ел (№ ____ ) кергән гариза (мөрәҗәгать) нигезендә, хуҗасыз булган билгеләре булган күчемсез мөлкәт объектын тикшерде.

Мөлкәтнең атамасы___________________________________________________
Мөлкәтнең урнашкан урыны___________________________________________________
Мөлкәтнкә кыскача тасвирлама___________________________________________
Мөлкәтнең хуҗасыз мөлкәткә кертелергә мөмкин булган билгеләре ____________
____________________________________________________________________________
Мөлкәтнең элеккеге хуҗасы _________________________________________________
Мөлкәт күпме вакыттан хуҗасыз ______________________________________

Комиссия әгъзаларының имзалары:

_________________ (имзаны расшифровкалау)

_________________ (имзаны расшифровкалау)

_________________ (имзаны расшифровкалау)

Хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне
ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү
Тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез милек объектлары
РЕЕСТРЫ

| № т/б | Объект атамасы | Объект урнашкан урын | Объектның кыскача тасвирламасы | №, объектны хуҗасыз дип тану турында администрация карары датасы | Теркәлүче органда исәпкә кую датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

«ТР Буа муниципаль районы
Башлыгының
«10» ноябрь 2020елнның
96-п номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча комиссиясе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча комиссиясе (алга таба - Комиссия) эше тәртибен билгели.

2. Комиссия компетенциясе

2.1. Комиссия Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез милек объектларын ачыклау буенча чаралар үткәрү максатларында төзелә.

2.2. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы раслаган ТР Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү тәртибе(алга таба- Тәртип) белән билгеләнә.

3. Комиссия эшен оештыру

3.1. Комиссия даими эшләүче коллегиаль орган булып тора, аның шәхси составы ТР Буа муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

3.2. Комиссиянең сан составы 3 кешедән дә ким була алмый.

Комиссия составына, әлеге органнар һәм оешмалар белән килештереп, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарының тармак бүлекчәләре һәм оешмалары вәкилләре кертелергә мөмкин.

3.3. Комиссия эше белән комиссия рәисе җитәкчелек итә, ә ул булмаганда - аны алмаштыручы зат.

3.4. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау буенча чаралар үткәрү датасын һәм вакытын билгели, Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча документларга кул куя (раслый), Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.5. Комиссия секретаре Комиссия эше өчен кирәкле мәгълүматны соратып ала, Комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган башка оешмаларга хуҗасыз күчемсез мөлкәтне ачыклау буенча планлаштырылган чаралар турында хәбәрнамәләр җибәрә, Тәртиптә каралган документларны төзи һәм аларның сакланышын тәэмин итә, эшчәнлек мәсьәләләре буенча комиссия рәисе йөкләмәләрен үти.

3.6. Комиссия әгъзалары комиссия эшендә катнаша, Комиссия эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә, Комиссия эше барышында кабул

ителә торган документларны имзалый, Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.7. Комиссия эшен матди-техник яктан тәэмин итүне Буа муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

«ТР Буа муниципаль районы
Башлыгының
«10» ноябрь 2020елның
96-п номерлы карарына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез һәм вариссыз калган мөлкәтне ачыклау, исәпкә алу һәм муниципаль милеккә рәсмиләштерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Камартдинов Р.Р. | - Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башлыгы (комиссия рәисе); |
| Мифтахов Ф.Ф. | - Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (комиссия рәисе урынбасары) (килешү буенча); |
| Шакирҗанов Л.Р. | - «Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе (комиссия секретаре); |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Габитов Р.Х. | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Галәветдинов Р.Я. | - Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Тазиев А.З. | - «ТР Техник инвентаризация бюросы»АҖ Буа шәһәре (килешү буенча); |
| Рахматов Б.Р. | - Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы; |
| ТР Буа муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары | - торак пунктка карап (килешү буенча) |